РЕШЕНИЕ КАРАР

№ 1 21.12.2019

**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Олы Шүрнәк авыл җирлегенең Үмәк торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 21 декбрендә, 14.00 сәгатьтә уздырылган гражданнардан үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча этаплы җыен нәтиҗәләреннән чыгып беркетмә төзелде.

Беркетмә нигезендә, гражданнар җыенының нәтиҗәләре түбәндәгеләр:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 52 кеше, тавыш бирүдә катнашучылар саны 40 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашучы 40 кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде;
«Тоткарланды» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып гражданнар җыены түбәндәгеләрне хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Олы Шүрнәк авыл җирлегенең Үмәк торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләрен- дөрес дип танырга.
2. «Сез Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Олы Шүрнәк авыл җирлегенең Үмәк торак пункты чикләрендә урнашкан даими яшәүче гражданнар һәм 18 яшькә җиткән кешеләр өчен 400 (дүрт йөз) сум күләмендә, гомуми авырудагы инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннар, күпбалалы гаиләләр, югары һәм урта-махсус (урта-һөнәри) уку йортларында белем алучы студентлар өчен 200 (ике йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкру буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме? »
соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:
-МТЗ-82.1 тракторына тагылма һәм асылмалы җиһазлар сатып алу;
- чүп контейнерларын сатып алу».
3. Әлеге карарның нәтиҗәләрен «Новая Кама» газетасында, Югары Шүрнәк авыл җирлегенең рәсми сайтында

(большешурнякское.городелабуга.рф.), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карар Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиеш.

Олы Шүрнәкы авыл җирлеге Башлыгы Н.И. Мельников